КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 25 ноябрь г.Казань № 1135

Татарстан Республикасы территориясендә хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә кош-кортларны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне оештыру һәм гамәлгә ашыру турында

«Ветеринария турында» 1993 елның 14 маендагы 4979-1 номерлы Россия Федерациясе Законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хайваннарның аеруча куркыныч авырулары чыганакларын бетергәндә хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 26 маендагы 310 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итү аркасында гражданнарга һәм юридик затларга килгән зыянны каплауга Татарстан Республикасы бюджеты акчасын тоту тәртибен раслау турында» 2018 ел, 14 февраль, 84 нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә кош-кортлар гриппының югары патогенлы вирусы чыганаклары барлыкка килүне булдырмау һәм бетерү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Калмаш авыл җирлеге, Калмаш авылы адресы буенча урнашкан, «Фролов Эдуард Александрович» крестьян (фермер) хуҗалыгына караган урыннар территориясендәге кош-кортларны һәм (яки) кошчылык продукциясен, шулай ук Тукай муниципаль районының Калмаш авылы, Новый поселогы, Югары Байлар авылы территориясендә авыл хуҗалыгы кош-кортларын алып юк итүне гамәлгә ашырырга.

2. Бу карарга теркәлгән Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия составын расларга.

3. Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын алып юк итүне гамәлгә ашыру буенча махсус комиссиягә бу карарның 1 пунктында каралган чараларның үтәлешен билгеләнгән тәртиптә оештырырга.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2021 ел, 25 ноябрь, 1135 нче
карары белән расланды

Хайваннарны һәм (яки) терлекчелек продуктларын
алып юк итүне гамәлгә ашыру буенча махсус комиссия
составы

| | |
|---|---|
| Мотыйгуллин Габделхак Госман улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары, махсус комиссия рәисе |
| Иванов Евгений Николаевич | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт ветеринария инспекторы, махсус комиссия рәисе урынбасары (килешү буенча) |

Махсус комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Гатин Идрис Мөдәррис улы | Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә караган дәүләт ветеринария күзәтчелеге бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Мифтахов Фәнис Хасият улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсенә караган Яр Чаллы территориаль ветеринария иминлеге һәм дәүләт күзәтчелеге бүлеге башлыгы |
| Ногманов Илдар Нургали улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Баш ветеринария идарәсе башлыгы урынбасары |
| Хәбибуллин Айрат Рафак улы | Тукай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Хәйбуллин Ленар Радик улы | «Тукай район дәүләт ветеринария берләшмәсе» дәүләт бюджет учреждениесе башлыгы. |

---